**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чемодур авыл җирлеге Советы**

Чемодур авылы №131 «23» апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чемодур авыл җирлегенең
2018 ел өчен бюджет үтәлеше турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чемодур авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең 2018 ел өчен бюджет үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 4 134,8 мең сум һәм чыгымнар буенча 3 997,8 мең сум күләмендә, 137,0 мең сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан 137,0 мең сум күләмендә артык булуын түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1) әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бюджет керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге бюджеты керемнәре;

2) әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бюджет чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

3) әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

4) әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат» рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aznakayevo.tatar.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Рәис Н.Б.Котельникова